РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.08.2019 Олы Кайбыч авылы № 45

**Кайбыч муниципаль районының гражданлык оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән яклау буенча укыту-консультация пунктлары булдыру турында**

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны укытуны оештыру турындагы нигезләмәне раслау турында» 2000 елның 02 ноябрендәге 841 номерлы карарын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 21 маендагы 1126-р номерлы боерыгын үтәү йөзеннән

**КАРАР ИТӘМ:**

1. Түбәндәге базада ГОГХ буенча укыту-консультация пунктлары булдырырга:

Ябалак авыл җирлегенең, Кошман авыл җирлегенең торак пунктлары составындагы хезмәт күрсәтү зоналарын беркетеп, «Кайбыч район мәдәният йорты» МСУ (Олы Кайбыч авылы);

Ульянково авыл җирлеге, Надежда авыл җирлеге, Багай авыл җирлеге торак пунктлары составындагы хезмәт күрсәтү зонасын беркетеп, «Олы Подберезье авылы мәдәният йорты» МСУ (Олы Подберезье авылы);

Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең, Иске Тәрбит авыл җирлегенең, Чүти авыл җирлегенең торак пунктлары составындагы хезмәт күрсәтү зонасын беркетеп, «Мәлки мәдәният йорты» МСУ (Мәлки авылы);

Хезмәт күрсәтү зонасын Олы Урсак авыл җирлегенең, Кече Мәми авыл җирлегенең, Борындык авыл җирлегенең, Федоровский авыл җирлегенең, Мөрәле авыл җирлегенең торак пунктларына беркетеп, «Колаңгы мәдәният йорты» МСУ (Колаңгы ст.п.).

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән авыл җирлекләре башлыкларына:

ГОГХ буенча укыту-консультация пунктлары эшчәнлеген булдыру һәм оештыру мәсьәләләре буенча кирәкле норматив документлар чыгарырга;

ГОГХ укыту-матди базасы буенча төзелә торган укыту-консультация пунктларын җиһазландыруда мәдәният йортлары (авыл клублары) җитәкчеләренә ярдәм күрсәтергә.

3. Укыту-консультация пунктларының составын штаттан тыш нигездә укыту-консультация пункты башлыгы һәм 1-2 инструктор составында формалаштырырга.

4. Кайбыч муниципаль районының гражданлык яклавы идарәсе җитәкчесенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән авыл җирлекләре башлыкларына ГОГХ буенча укыту-консультация пунктларын төзүдә һәм оештыруда методик һәм гамәли ярдәм күрсәтергә.

5. ГОГХ буенча укыту-консультация пунктларын төзү гамәлләрен финанслауны Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчалары исәбеннән гамәлгә ашырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы рәсми сайтында бастырырга http:/kaybici.tatarstan.ru//.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны һәм ярдәм күрсәтүне Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А.Н. Макаровка йөкләргә.

**А. И. Рәхмәтуллин**